

Икенче марттан 6 мартка кадәр әлеге мәктәптә чит һәм туган телләр атналыгы (татар һәм мордва) vткәрелгән.
Предмет атнасынын топ максаты - укучыларнын телләргә һәм аларнын мәдәниятенә кызыксынуын арттыру, туган телләрне саклау, популярлаштыру, хормәт тәрбияләv.
Предмет атналыгы кысаларында туган татар теле һәм мордва теле укытучылары Алмаз Кериш кызы Янгляева һәм Марина Витальевна Пирогова 2 нче сыйныфларда гадәти булмаган ижади юнәлешле дәресләр vткәрделәр. Татар теле укытучысы Алмаз Кериш кызы балаларны татар орнаменты һәм анын татар милли киемнәре тегvдә кулланылуы белән таныштырган. Дәреснен практик олешендә укучылар, укытучылары белән бергә, 8 мартка әниләргә татар орнаменты кулланып котлау открыткалары әзерләгәннәр.
Туган әрзә теле укытучысы Марина Витальевна укучыларны мордва милли киеме белән таныштырган һәм презентациядә мордва халкынын матур киеме турындагы материалны кvрсәткән. Теманы яктырткан викторинада укучылар актив катнашкан. Дәресләр эчтәлекле һәм кызыклы vткән.
Туган телегезне яратыгыз, сой-ләгез, укыгыз. Туган телләрегезне саклагыз, vстерегез һәм популярлаштырыгыз.